**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

16 нчы февраль 2021 ел **№ 40** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2013 елның 28 октябрендәге 170 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең чик санын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының тәкъдимен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2013 елның 28 октябрендәге 170 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең чик санын билгеләү турында» карарына (19.12.2013 № 188, 26.05.2014 № 212, 27.11.2014 № 234, 17.04.2015 № 263, 22.04.2016 № 47, 12.04.2018 № 128, 24.08.2018 № 142, 28.03.2019 № 172, 21.08.2019 № 186, 18.09.2019 №193, 20.11.2019 № 208, 20.01.2020 № 225, 23.09.2020 № 7, 29.12.2020 № 31) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инвестиция эшчәнлеге секторын оештырырга».

1.2. «Җитәкче урынбасары – территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге башлыгы», вазыйфасын «Җитәкче урынбасары – территориаль үсеш бүлеге башлыгы» дип үзгәртергә.

1.3. «Территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге» н «территориаль үсеш бүлеге» дип үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы Башлыгы Н. Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль район Советының 2021
елның 16 нчы февраленнән  40 нчы
номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасы

